ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 апрель, 2022 ел № 14/10

Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми кулланыштагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 декабрендәге 445-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы 2 өлеше 68 пункты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/10, 2020 елның 11 августындагы 41/11, 2021 елның 18 мартындагы 6/14 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) зиратлар, үләт базларын, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру объектларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулы һәм агулый торган матдәләр, радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру, шулай ук территорияне балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектлары өчен рөхсәт ителгән иң чик концентрацияләре билгеләнмәгән пычрата торган матдәләр белән пычрату»;

2) 27 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) зиратлар, үләт базларын, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру объектларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулы һәм агулый торган матдәләр, радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру, шулай ук территорияне балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектлары өчен рөхсәт ителгән иң чик концентрацияләре билгеләнмәгән пычрата торган матдәләр белән пычрату».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев